**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1027

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында лизинг рәвешендәге инвестицияләрне үстерү чаралары турында» 2006 ел, 28 февраль, 79 нчы карары белән расланган «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе уставына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында лизинг рәвешендәге инвестицияләрне үстерү чаралары турында» 2006 ел, 28 февраль, 79 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 декабрь, 1088 нче; 2013 ел, 24 июнь, 437 нче, 2015 ел, 3 июнь, 405 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле егерменче – утыз сигезенче абзацлар өстәргә:

«китаплар нәшер итү,

газеталар нәшер итү,

журналлар һәм вакытлы басмалар нәшер итү,

тавыш язмалары нәшер итү,

нәшрият эшчәнлегенең бүтән төрләре,

газеталар бастыру,

башка төркемнәргә кертелмәгән полиграфия эшчәнлеге,

төпләү-тышлау һәм бизәү эшчәнлеге,

басма формалар әзерләү,

бүтән полиграфия эшчәнлеге,

телекибетләр һәм компьютер челтәрләре аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату (электрон сату, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп),

исәпләү техникасы аппарат чаралары аша консультация бирү,

программалар белән тәэмин итүне эшләү һәм бу өлкәдә консультация бирү,

мәгълүматлар белән эшләү;

мәгълүматлар базасын һәм мәгълүмат ресурсларын булдыру һәм куллану эшчәнлеге,

офис машиналарын һәм исәпләп чыгару техникасын техник карап тору һәм төзәтү,

исәпләп чыгару техникасын һәм мәгълүмат технологияләрен файдалану белән бәйле бүтән эшчәнлек,

реклама эшчәнлеге,

мәгълүмат агентлыклары эшчәнлеге,»;

егерменче абзацны утыз тугызынчы абзац дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1027.docx